Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.12.2022 ел Менделеевск ш. №755

Объектка карата территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында: «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Карпов исемендәге заводка илтүче автомобиль юлы төзү»

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьясы нигезендә территорияне тотрыклы үстерүне һәм планлаштыру структурасы элементларын аерып алуны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан объектка территорияне планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын расларга: «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәрендә Карпов исемендәге заводка керү юлы төзү.

Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә билгеләнгән тәртип нигезендә территорияне планлаштыруның расланган проектын һәм аны ызанлау проектын теркәүне түбәндәге объектка уздырырга: «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Карпов исемендәге заводка илтүче автомобиль юлын төзү».

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Искаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров

Килештерелде
Җитәкченең беренче урынбасары
вазыйфасын башкаручы А.Ф.Исхаков

Җитәкче урынбасары С.В. Метальников

Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

Башкаручы Хәбиров Р.З.
8(85549)2-01-99